ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 17.07.2025 1166 КАРАР

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елның 2 яртыеллыгына торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондына караган торак урыннарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2025 елның 26 июнендәге 1072 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 30 статьяның 3 өлеше, 37 статьяның 1 өлеше, 39 статьяның 2 өлеше, 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милекнең тиешле эчтәлеген тәэмин итү өчен кирәкле хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеге һәм аларны күрсәтү һәм үтәү тәртибе турында» 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Йорт эчендәге һәм квартал эчендәге газ җиһазларын файдаланганда һәм тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итү чаралары турында» 2013 елның 14 маендагы 410 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елның 2 яртыеллыгына торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), муниципаль торак фондына караган торак урыннарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урын милекчеләре өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2025 елның 26 июнендәге 1072 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы 2 пунктында хезмәт күрсәтү исемендәге
« - торак биналарның конструктив элементларына агымдагы ремонт һәм йорт яны территориясен төзекләндерү» сүзләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« - торак биналарның конструктив элементларына агымдагы ремонт».

1.2. Әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Түләү алынучы үлчәнеш берәмлеге (айга), сум. | Күрсәтелгән хезмәтнең үлчәнеш берәмлеге буенча тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| | | | 01.07.2025 - 31.12.2025 |
| 4 | Сыек көнкүреш калдыкларын суыртту һәм чыгару | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 13,62 |

1.3. Әлеге карарның 1 нче кушымтасын түбәндәге эчтәлектәге 6 пункт белән тулыландырырга:

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Түләү алынучы үлчәнеш берәмлеге (айга), сум. | Күрсәтелгән хезмәтнең үлчәнеш берәмлеге |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | буенча тариф (сумнарда) |
| | | | с 01.07.2025 по 31.12.2025 |
| 6 | Йорт эчендәге газ җиһазына техник диагностика ясау (түләү диагностика ясау срогы башланганчы 12 ай эчендә исәпләнә) | торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. | 0,58 |

2. Әлеге карар рәсми төстә бастырып чыгарылырга тиеш һәм гамәлдә булу чоры 2025 елның 1 августыннан башлап барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5D5B832C0D4CC8A96C405A04F5061337

Владелец: Томилин Андрей Александрович

Действителен с 25.09.2024 до 19.12.2025

А.А. Томилин